М Э Р
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.01.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 02-03-01**

Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы адресы буенча, 20Б җир кишәрлеге территориясен ызанлау проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә ,Татарстан Республикасының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы адресы буенча, 20 нче җир кишәрлеге территориясен ызанлау проекты буенча, Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләрнең җәмәгатьчелек фикер алышу юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатларында,

**КАРАР КЫЛАМ:**

1. Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, адресы буенча 20 нчеҗир кишәрлеге территорияне ызанлау проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышуны билгеләргә (алга таба - Проект).
2. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрү срогы - 22.01.2026 - 12.02.2026.
3. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуда каралырга тиешле Проект экспозициясен ачу 29.01.2026:
3.1. Экспозицияне үткәрү срогы 8 көн 29.01.2026 - 05.02.2026;
3.2. Экспозицияне үткәрү урыны:
- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының http://zelenodolsk.tatarstan.ru рәсми сайтында «Территориаль планлаштыру документлары» бүлегендә;
- мәгълүмати стендларда:
Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында;
3.3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында экспозицияне карау вакыты: Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорт,

дүшәмбе-җомгага 8.30 дан 16.30 га кадәр (эшләми торган, бәйрәм көннәреннән тыш).

4. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда катнашучылар 29.01.2026 елдан 05.02.2026 елга кадәр җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кертергә хокуклы:

1) Зеленодольск муниципаль районының рәсми http://zelenodolsk.tatarstan.ru сайты интернет-кабул итү бүлмәсе аша.

2) җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыручыга язма рәвештә Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорт адресы буенча , 211 нче кабинетта;

3) Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты адресы буенча, 211нче кабинта җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне теркәү китабына (журналга) язылу юлы белән.

4.1. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (физик затлар өчен (фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), туган көнен, яшәү (теркәлү) урыны адресын; юридик затлар өчен исемен, төп дәүләт теркәү номерын, урнашу урыны һәм адресын ), мондый белешмәләрне раслый торган документлар кушымтасы белән тапшыралар. Күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) биналарына хокук ияләре булган җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда катнашучылар шулай ук тиешенчә мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булып торган биналар турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан белешмәләр һәм күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, биналарга аларның хокукларын билгели яисә таныклый торган башка документлар тапшыра.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлергә, шулай ук җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыручы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш, җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда катнашучының дөрес булмаган белешмәләр тапшыру фактлары ачыкланганнан тыш.

5. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыручы итеп «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ исеменнән Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитетын билгеләргә. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыручыга:

5.1. 22.01.2026 елда «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми http://zelenodolsk.tatarstan.ru сайтында Проект буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышулар башлануы турында хәбәр урнаштырырга;

5.2. 29.01.2026 елдан 05.02.2026 елга кадәрге вакытта идентификация узган җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда катнашучылардан фикер алышу Проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итәргә:

- электрон рәвештә Зеленодольск муниципаль районының рәсми http://zelenodolsk.tatarstan.ru сайтында ;

- язма рәвештә Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорт адресы буенча, 211 нче кабинетта (дүшәмбе- җомга 8.30 дан 16.30 га кадәр һәм 13.30 дан 16.30 га кадәр (эшләми торган, бәйрәм көннәреннән тыш).

- Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты адресы буенча, 211нче кабинетта җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда каралырга тиешле Проект экспозициясенә килүчеләрне теркәү китабына (журналга) язылу юлы белән (дүшәмбе-җомга көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр һәм 13.30 дан 16.30 га кадәр).

5.3. җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләре буенча беркетмә һәм җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә;

5.4. 12.02.2026 елда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми http://zelenodolsk.tatarstan.ru сайтында җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Зеленодольск шәһәре Хакиме** **М.П. Афанасьев**